**Республика Татарстан**
**ГлаваУрсаевского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Зәймуниципаль районы**
**Урсай авыл җирлеге**
**башлыгы**

ул. Центральная, д.5, с. Урсаево, Заинский район, 423535

Центральна яурамы, 5нче йорт, Урсай авылы, Зәй районы, 423535

Телефон, факс 2-80-46. Электронный адрес:Usaev.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
16.11.2019 ел № 4

**«2020 елга һәм 2021 - 2022 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлаулар билгеләү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Уставы һәм Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә таянып

## карар бирәм:

1. «2020 елга һәм 2021 - 2022 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы карар проекты буенча ачык (гавами) тыңлауларны 2019 елның 26 ноябрендә 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Урсай ав., Үзәк ур., 5 й.

2. 2020 елга һәм 2021 - 2022 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге бюджеты проектындагы материаллар белән танышырга мөмкин:

- Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлегенең рәсми сайтында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында;
- текст өлеше белән «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге администрациясе бинасында, адресы: Урсай ав., Үзәк ур., 5 й.

3. «2020 елга һәм 2021 - 2022 еллар план чорына Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге бюджеты турында» Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы карар проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр язмача

рәвештә 423535, Зәй районы, Урсай авылы, Үзәк ур., 5 йорт адресы буенча җибәрелә (конвертта «бюджет турында фикер алышу» дигән тамга белән).

4. Законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиягә, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Советы каравына чыгарырга.

5. Әлеге карарны һәм ачык тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча беркетмәне Зәй муниципаль районы сайтының (http://zainsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы** **Н.Ә. Гатина**